РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«2» ноября 2023г. г. Альметьевск №121

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2014 елның 2 октябрендәге 148 номерлы «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мелкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мелкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2014 елның 2 октябрендәге 148 номерлы «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мелкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мелкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 156 номерлы, 2015 елның 7 августындагы 186 номерлы, 2020 елның 23 июнендәге 202 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 23 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 78 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе» 2 бүлегенең 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Керемнәр, чыгымнар, мелкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә тапшырыла.»;

- 1 нче кушымтаның 3 бүлегендәге 3.1. пунктын «Гражданнарның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мелкәти

характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырган өчен җаваплылыгын» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Граждан үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында муниципаль хезмәткә килгәндә, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр тапшырганда йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшырганда күрсәтелгән гражданны муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

- 1 нче кушымтаның 3 бүлегендәге 3.2 пунктын «Гражданнарның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырган өчен җаваплылыгы» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшырсалар йә тулы булмаган белешмәләрне тапшырсалар, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

- 1 нче кушымтаның «Гражданнарның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырган өчен җаваплылыгы» 3 бүлегенең 3.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.2.1. пунктчасы өстәргә:

«3.2.1. Муниципаль хезмәткәрләргә 3.2 пунктында күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

- «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр белән эшләү тәртибе» 4 бүлегенең 4.3 пунктында комиссия исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия. ».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Шәйхетдинова Ф.А.) .

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов